СОВЕТ МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

01.04.2026 с.Майдан № 8– 44

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советның кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

"Коррупциягә каршы көрәш турында" 25.12.2008 елгы 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Көчен югалткан дип танырга:

1.1. "Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында" Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының 06.03.2023 ел № 28-156 карары;

1.2. "Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары күрү тәртибен раслау турында" Мәйдан авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 июнендәге 69-321 номерлы карары;

1.3. "Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук, әгәр бу мәгълүматларны бозу гамәлдә булмаса, үз иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында Карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында" Мәйдан авыл җирлеге Советының 06.03.2023 елның 28-158 номерлы карары;

1.4. «Мәйдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән. “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм

мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен раслау турында» Югары Ослан муниципаль районы Советының 25.09.2017 елның 30-135 номерлы карары .

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга мөмкин.

Председательлек итүче,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев